**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

28.01.2020 89-п

«Татарстан Республикасы территориясендә сәнәгать, энергетика, транспорт һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр өчен рекультивация һәм башка торгызу эшләре үткәрелгәннән соң гадәти кара җирле, ачык соры төстәге урман, соры урман, куе соры урман, кәсле-көлсу, кәсле-карбонатлы эретелгән, кәсле-карбонатлы көлсуланган туфракларда һәм грунтларда калырга мөмкин булган нефть һәм аның трансформацияләнү продуктларының калдык микъдары» төбәк нормативларын раслау турында

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль законның 6 статьясын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 06 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмә, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан туфрак сыйфатының төбәк нормативларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2013 елның 10 июлендәге 382-п номерлы боерыгы нигезендә, әйләнә-тирә мохиткә булган хуҗалык яки башка төр эшчәнлек йогынтысын җайга салу максатларында боерык бирәм:

1. «Татарстан Республикасы территориясендә сәнәгать, энергетика, транспорт һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр өчен рекультивация һәм башка торгызу эшләре үткәрелгәннән соң гадәти кара җирле, ачык соры төстәге урман, соры урман, куе соры урман, кәсле-көлсу, кәсле-карбонатлы эретелгән, кәсле-карбонатлы көлсуланган туфракларда һәм грунтларда калырга мөмкин булган нефть һәм аның трансформацияләнү продуктларының калдык микъдары»ның кушымтада бирелгән төбәк нормативларын (алга таба – нефть һәм аның трансформацияләнү продуктларының калдык микъдары төбәк нормативлары) расларга.

2. Нефть һәм аның трансформацияләнү продуктларының калдык микъдары төбәк нормативларының гамәлдә булу чорын әлеге Боерык басылып чыккан вакыттан

башлап вәкаләтле федераль дәүләт хакимияте органнары тарафыннан әйләнә-тирә мохит сыйфатының тиешле нормативлары кертелгәнчегә кадәр билгеләргә.

3. Хокукый тәэмин итү бүлегенә (М.М. Шәехов) әлеге Боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

4. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.М. Шиһаповка йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать ресурслары
министрлыгының 2020 елның 28
гыйнварындагы 89-п номерлы
боерыгы белән расланды

«Татарстан Республикасы территориясендә сәнәгать, энергетика, транспорт һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр өчен рекультивация һәм башка торгызу эшләре үткәрелгәннән соң гадәти кара җирле, ачык соры төстәге урман, соры урман, куе соры урман, кәсле-көлсу, кәсле-карбонатлы эретелгән, кәсле-карбонатлы көлсуланган туфракларда һәм грунтларда калырга мөмкин булган нефть һәм аның трансформацияләнү продуктларының калдык микъдары»
төбәк нормативлары

1. Әйләнә-тирә мохитнең сыйфат нормативларына карый торган «Татарстан Республикасы территориясендә сәнәгать, энергетика, транспорт һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр өчен рекультивация һәм башка торгызу эшләре үткәрелгәннән соң гадәти кара җирле, ачык соры төстәге урман, соры урман, куе соры урман, кәсле-көлсу, кәсле-карбонатлы эретелгән, кәсле-карбонатлы көлсуланган туфракларда һәм грунтларда калырга мөмкин булган нефть һәм аның трансформацияләнү продуктларының калдык микъдары» төбәк нормативлары (алга таба – нефть һәм аның трансформацияләнү продуктларының калдык микъдары төбәк нормативлары) Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының 2002 елның 12 сентябрендәге 574 номерлы боерыгы белән расланган Рекультивация һәм башка төрле торгызу эшләрен уздырганнан соң туфракларда нефтьнең һәм аның трансформацияләнү продуктларының мөмкин булган калдык микъдары нормативларын эшләү һәм гамәлгә кертү буенча вакытлыча күрсәтмәләр нигезендә, Татарстан Республикасында җирдән файдалану төрен һәм туфракларның классификацияләрен (1-3 нче таблицалар) исәпкә алып эшләнде һәм Татарстан Республикасы территориясендә сәнәгать, энергетика, транспорт һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр өчен рекультивация һәм башка торгызу эшләре үткәрелгәннән соң гадәти кара җирле, ачык соры төстәге урман, соры урман, куе соры урман, кәсле-көлсу, кәсле-карбонатлы эретелгән, кәсле-карбонатлы көлсуланган туфракларда һәм грунтларда калырга мөмкин булган нефть һәм аның трансформацияләнү продуктларының мөмкин булган калдык микъдарын билгели.

2. Нефть һәм аның трансформацияләнү продуктларының калдык микъдары төбәк нормативлары туфракларның һәм җирләрнең нефть углеводородлары белән пычрану дәрәҗәсен чикләү һәм регламентлау, туфрак экосистемаларына тискәре йогынтыны бетерү максатларында билгеләнә.

3. Нефть һәм аның трансформацияләнү продуктларының калдык микъдары төбәк нормативлары рекультивация һәм башка торгызу эшләре башкарылганнан соң туфракның һәм җирләрнең торышын бәяләгәндә контрольлек итүче органнар һәм хуҗалык итүче субъектлар тарафыннан куллану өчен билгеләнә.

4. Нефть һәм аның трансформацияләнү продуктларының калдык микъдары төбәк нормативлары ГОСТ Р 8.589-2001 «Үлчәм алуларның бердәмлеген тәэмин итү дәүләт системасы. Әйләнә-тирә табигый мохитнең пычрануын тикшерүдә тоту.

Метрологик тәэмин итү. Төп нигезләмәләр», РД 52.18.575-96 «Туфрак пробаларында инфракызыл спектрометрия ысулы белән нефть продуктларының тулай микъдарын билгеләү. Үлчәүләрне үтәү методикасы», ПНД Ф 16.1:2.2.22-98 «ИК-спектрометрия алымы белән минераль, органоген, орган-минераль туфракларда һәм төн катламнарында нефть продуктларының массакүләм микъдарын үлчәү методикасы» һәм ПНД Ф 16.1:2.21-98 «Туфракларга санлы химик анализ. Су сыгынтысының тыгыз калдык микъдарының ГОСТ 26423-85 «Туфраклар. Чагыштырма электр үткәрү дәрәҗәсен, pH һәм су сыгынтысының тыгыз калдык микъдарын билгеләү алымнары» нигезендә ачыкланган күләмендә «Флюорат-02» сыеклыгы анализаторын кулланып, флуориметрик алым белән туфрак пробаларында һәм грунт пробаларында нефть продуктларының массакүләм микъдарын үлчәү методикасы» нигезендә ачыкланган нефть углеводородларының массакүләм микъдарына исәпләгәндә нефть продуктлары өлешенә тигез итеп кабул ителә.

Туфракларның пробалары ГОСТ 17.4.3.01-2017 «Табигатьне саклау. Туфраклар. Пробалар алуга карата гомуми таләпләр», ГОСТ 17.4.4.02-2017 «Табигатьне саклау. Туфраклар. Химик, бактериологик, гельминтологи анализ өчен пробаларны сайлап алу һәм әзерләү алымнары», ГОСТ Р 58595-2019 «Туфраклар. Пробалар сайлап алу» нигезендә сайлап алына.

1 нче таблица

# «Татарстан Республикасы территориясендә сәнәгать, энергетика, транспорт һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр өчен рекультивация һәм башка торгызу эшләре үткәрелгәннән соң гадәти кара җирле, ачык соры төстәге урман, соры урман, куе соры урман, кәсле-көлсу, кәсле-карбонатлы эретелгән, кәсле-карбонатлы көлсуланган туфракларда һәм грунтларда калырга мөмкин булган нефть һәм аның трансформацияләнү продуктларының калдык микъдары» төбәк нормативлары

1. Урман-дала зонасы 06
(туфрак-география зонасы/зона өлеше)

2. Сәнәгать, энергетика, транспорт һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр 5
(җирләрнең максатчан билгеләнеше, торгызу эшләре башкарылганнан соң җир кишәрлекләрен файдалану төре)

| Туфраклар | | | | Туфрак горизонт-лары (индекс), яки катламнар (тирәнлек-ләр) | Норматив күрсәт-кече, г/кг | Рекультивацияләнгән кишәрлекне кабул итү буенча таләпләр | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Төргә караган төркем | Гранула-метрик составы | Коды | Типлары | | | Норматив күрсәткеч артып киткән, рөхсәт ителгән мәйдан (рекультивацияләнгән кишәрлек мәйданыннан%) | Өстәмә таләпләр (кирәк булганда) |
| Органоминераль табигый һәм антропоген үзгәртеп корылган туфраклар | Җиңел һәм уртача балчыксыл туфрак, Авыр балчыксыл туфрак һәм балчык | 22<br>23 | Кәсле-көлсу, кәсле-карбонатлы көлсуланган, кәсле-карбонатлы эретелгән, ачык соры урман, соры урман, куе соры урман | А1, В | 11,0 | 10 | Тозларның гомуми микъдары (су сыгынтысының тыгыз калдык өлеше) 0,15% артмый |
| Органоминераль табигый һәм антропоген үзгәртеп корылган туфраклар | Җиңел һәм уртача балчыклы туфрак, авыр балчыклы туфрак һәм балчык | 22,<br>23 | Көлсуланган кара туфраклар, кара туфраклар эретелгән, гадәти кара туфраклар | А1, В | 12,0 | 10 | Тозларның гомуми микъдары (су сыгынтысының тыгыз калдык өлеше) 0,15% артмый |
| Туфраксыман антропоген туфраклар | Теләсә кайсы | 31,<br>32,<br>33 | - | 0-20 см | 15,0 | 10 | Тозларның гомуми микъдары (су сыгынтысының тыгыз калдык өлеше) 0,15% артмый |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Минераль грунтлар | Теләсә кайсы | 41, 42, 43 | - | 0-20 см | 15,0 | 10 | Тозларның гомуми микъдары (су сыгынтысының тыгыз калдык өлеше) 0,15% артмый |

2 таблица

Туфрак горизонтлары индексациясе

| Туфрак горизонты индексы | Туфрак горизонтының атамасы |
|---|---|
| Ao | югарыгы туфрак катламы (урман түшәмәсе) |
| Ат | каты черемәле, торфланган катлам |
| Ad | кәс |
| Al | черемәле, кәсле катлам |
| Aпах | сөрүлек катламы |
| A2 | көлсу горизонт (ашалу) |
| B | иллювиаль катлам (ашалу) |
| Bh | иллювиаль-черемәле горизонт |
| Bf | иллювиаль-тимерле горизонт |
| T | төрле дәрәҗәдә таркалган торфлы горизонт |
| Оч | чүбек (тере мүкләрнең һәм мүкле киезнең өске катламы) |

3 нче таблица

| Табигый-климат зоналары кодлары | | |
|---|---|---|
| Табигый-климат зонасы | | Коды |
| Субарктик | | 01 |
| Тундра һәм урман-тундра | | 02 |
| Төньяк тайга | | 03 |
| Урта тайга | | 04 |
| Көньяк тайга | | 05 |
| Урман-дала | | 06 |
| Дала | | 07 |
| Коры-дала | | 08 |
| Ярымдала | | 09 |
| Субтропик | | 10 |
| Җирләрне рекультивацияләү юнәлешләре кодлары | | |
| Рекультивация юнәлеше | | Коды |
| Авыл хуҗалыгы | | 1 |
| Урман хуҗалыгы | | 2 |
| Су хуҗалыгы | | 3 |
| Рекреацион | | 4 |
| Төзелеш | | 5 |
| Табигать саклау | | 6 |
| Санитар | | 7 |
| Типларга караган төркемнәрнең кодлары | | |
| Төргә караган төркем | Төркем эчендәге үзенчәлекләр | Коды |
| Органоген туфраклар | Өске<br>Аскы | 11<br>12 |
| Органоминераль табигый һәм антропоген үзгәртеп корылган туфраклар | Ком һәм комлы туфрак<br>Җиңел һәм уртача балчыксыл туфрак<br>Авыр балчыксыл туфрак һәм балчык | 21<br>22<br>23 |
| Туфраксыман антропоген туфраклар | Ком һәм комлы туфрак<br>Җиңел һәм уртача балчыксыл туфрак<br>Авыр балчыксыл туфрак һәм балчык | 31<br>32<br>33 |
| Минераль грунтлар | Ком һәм комлы туфрак<br>Җиңел һәм уртача балчыксыл | 41<br>42 |

| | | |
|---|---|---|
| | туфрак<br>Авыр балчыксыл туфрак һәм балчык | 43 |